РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
29 май 2025 ел

КАРАР
№ 8

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының «Норлат авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 14 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6 пунктның «б» пунктчасында «шулай ук теркәлү карточкаларында яисә йорт кенәгәләрендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккач законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Норлат авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе М.Х.Закиров